**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_05__» ____02___ 2024 ел.** **№ ___24___**

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендәге яки ялгыз яшәүче гражданның салым түләргә тиешле мөлкәтенең бәясен билгеләү турында

"Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм әлеге законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Азнакай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метр бәясенең нормасын билгеләү турында» 2024 елның 05 февралендәге 19 номерлы карары нигезендә, карар бирә:

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

1.1.1 ялгыз яшәүче граждан өчен - 928 458 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 1 856 916 сум;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен - 2 785 374 сум;
1.1.4 дүрт кешедән торган гаилә өчен - 3 713 832 сум;
1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен - 4 642 290 сум;
1.1.6 алты кешедән торган гаилә өчен - 5 570 748 сум;
1.1.7 җиде кешедән торган гаилә өчен - 6 499 206 сум;
1.1.8 сигез кешедән торган гаилә өчен - 7 427 664 сум;
1.1.9 тугыз кешедән туган гаилә өчен - 8 356 122 сум;
1.1.10 ун кешедән торган гаилә өчен - 9 284 580 сум.

1.2 Граждан гаиләсенең бер әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме 35 204 сум 03 тиен тәшкил итә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов